РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ГЛАВА ЧУЛПАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЧУЛПАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Чулпан ав. КАРАР

«30» октябрь 2020 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 10 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Чулпан авылы, М. Җәлил урамы, 70 нче йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында Үзәк урамы, Кыр, Күл, Подстанция, Көнчыгыш, Болын, Лермонтов урамнарында, Лермонтов тыкрыгында, Гоголь урамында яшәүче гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Чулпан авылы, М. Җәлил урамы, 70 нче йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында Шоссе урамы, Тукай, М.Җәлил, Елга арьягы, урамнарында яшәүче гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2020 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Чулпан авылы, М. Җәлил урамы, 70 нче йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында Мәктәп урамы, Төньяк, Бакча, Пушкин, Овражная, Хастаханә территориясе урамнарында яшәүче гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында яшәүчеләрнең исемлеген гражданнар җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча бүләргә.

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлегендә халык җыены этапларын уздыру һәм оештыруны Чулпан авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган, 1 гр инвалидлардан

тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм грунтлы вак таш салу;

Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;

Садовая, Үзәк һәм Тукай урамнарына янгын сүндерү гидрантлары сатып алырга һәм урнаштырырга;

Урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

7.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Чулпан авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Зыятдинов